# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«06» 12 2022 ел Яр Чаллы №359

2023 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 2021 елның 22 сентябрендәге 01/1810 номерлы хаты нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга расларга:

1.1. 2023 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын 1 кушымта нигезендә.

1.2. Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне 2 кушымта нигезендә.

2. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 06 ______ ______ номерлы карарына 1 кушымта

2023 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумнарда | автотранспорт чарасы узган бер километрга ставка, сумнарда |
| КАВЗ | 613418 | 20,86 |
| ПАЗ | 613675 | 21,02 |
| ГАЗ «Газель» | 593227 | 13,56 |
| УАЗ | 592774 | 11,87 |
| FIAT | 596122 | 9,98 |
| Peugeot Boxer | 601272 | 9,61 |
| Ford Transit | 601529 | 13,74 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 615632 | 18,67 |

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 06 ______ ______ санлы карарына 2 кушымта

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы йөреше нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик йөреше турында мәгълүмат, автотранспорт чарасының расланган маршруты паспорты кысаларында автотранспорт чарасының хисап елында факттагы йөреше буларак, Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы белешмәләре буенча кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. Муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - $m$ моделендәге автотранспорт чараларының фактик йөреше, километрларда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы ставкасы, бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумнарда;

$M_m$ - $m$ моделендәге автотранспорт чаралары саны, берәмлекләрдә;

$m$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус моделенең исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләренең саны.